КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 ноябрь г.Казань № 1029

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе коллегиясе составын раслау турында» 2013 ел, 20 июнь, 423 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе коллегиясе составын раслау турында» 2013 ел, 20 июнь, 423 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 23 сентябрь, 702 нче; 2017 ел, 8 август, 564 нче; 2018 ел, 16 апрель, 255 нче; 2019 ел, 6 декабрь, 1113 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составына Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсенең күзәтчелек һәм автоматлаштырылган исәпкә алу бүлеге башлыгы Рәдис Рафил улы Кадыйровны кертергә;

Андрей Николаевич Герасимовның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсенең аттракционнарга күзәтчелек итү һәм урамнан тыш траспортны дәүләт тикшерүендә тоту бүлеге башлыгы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин